**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 15 августындагы 3362 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 июнендәге 2707 номерлы**
**«Казан шәһәрендә «Төнге Казан – 2024» җиңел атлетика чарасын үткәрү, чараны әзерләү һәм үткәрү чорына транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Техник хата булу сәбәпле **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 26 июнендәге 2707 номерлы «Казан шәһәрендә «Төнге Казан – 2024» җиңел атлетика чарасын үткәрү, чараны әзерләү һәм үткәрү чорына транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбулада «2007 елның 8 маендагы 257-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында”гы» сүзләрен «2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.1. пунктындагы 1 абзацына «карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә» сүзләрен өстәргә;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**